КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 04 июль г.Казань № 804

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингы турында» 2010 ел, 31 март, 205 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингы турында» 2010 ел, 31 март, 205 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 21 декабрь, 1046 нчы; 2019 ел, 20 май, 406 нчы; 2020 ел, 18 март, 200 нче; 2020 ел, 30 апрель, 351 нче; 2020 ел, 25 сентябрь, 865 нче; 2021 ел, 5 апрель, 214 нче, 2023 ел, 18 апрель, 485 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингы өчен мәгълүмат урнаштыру (бирү) регламентында:

2 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин